ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www.agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» гыйнвар 2020г. № 09

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 1 мартындагы 68 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 02 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар өчен льготалы категория гражданнар исемлегенә өстәмәләр кертү өлешендә, «Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 01 октябрендәге 328-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Башкарма хакимиятнең кайбер федераль органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (2019 елның 1 октябренә үзгәрешләр белән), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 26 июлендәге 963 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контртеррористик операцияләрдә катнашучы һәм Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүче федераль башкарма хакимият органнары хәрбиләренә һәм хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» 2004 елның 09 февралендәге 65 номерлы карары нигезендә (2019 елның 24 декабренә үзгәрешләр белән), ««Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма

комитетының 2009 елның 01 мартындагы 68 номерлы карарына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы прокуратурасының 2020 елның 09 гыйнварындагы 02-08-01/2 номерлы протестын исәпкә алып, норматив базаның законнарга туры килүен тәэмин итү максатыннан чыгып, законнар һәм муниципаль актларга үткәрелгән мониторинг нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 1 мартындагы 68 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1.2. пунктының алтынчы абзацында:

«- Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ регионы территориясендә террорчылык оешмалары һәм төркемнәренең, гаскәрләрнең (көчләрнең) берләштерелгән төркемнәренең эшчәнлеген ачыклау һәм туктату буенча махсус көчләр хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләрнең балалары;» сүзләрен

«-Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте учреждениеләре һәм хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм контртеррористик операцияләрдә катнашучы һәм Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ регионы территориясендә террорчылык оешмалары һәм төркемнәренең, аларның лидерларының һәм Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ регионы территориясендә террорлык акцияләрен оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашучы затларның, шулай ук гаскәрләрнең (көчләрнең) берләштерелгән төркеме хезмәткәрләренең һәм хәрбиләренең эшчәнлеген ачыклау һәм туктату буенча махсус көчләр составына керүче Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ регионы территориясендә терроризмга каршы операцияләр үткәрү буенча хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүче затларның балалары;"; сүзләренә алмаштырырга

б) 1.2. пунктының уналтынчы абзацында:

«- махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, янгынга каршы дәүләт хезмәте Федераль хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, шул исәптән хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган имгәнү яки башка зыян нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләрнең балалары; хезмәт үтү вакытында алынган авырулар нәтиҗәсендә вафат булган; алга таба хезмәт итү мөмкинлегеннән төшереп калдырган, гарипләнү яки башка зыян китерү аркасында эштән киткән, хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган имгәнү яки башка зыян китерү аркасында вафат булган, йә хезмәт узу чорында алынган авыру нәтиҗәсендә, хезмәт үтү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән хезмәткәр, Россия Федерациясе гражданы тәрбиясендә булган балалар» сүзләрен

«-махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәү органнарында, дәүләт янгынга каршы хезмәте Федераль хезмәтендә һәм Россия Федерациясенең таможня органнарында хезмәт итүче хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе гражданнарыныц, җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясенец мәҗбүри үтәү органнарында, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең Федераль хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүдән азат ителгән хезмәткәрләренең балалары.» сүзләренә алмаштырырга.

в) яңа унтугызынчы абзац белән тулыландырырга:

«Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар мәктәпкәчә белем һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бертуганнары белем алган дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына өстенлекле кабул итү хокукына ия.»;

2. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУна мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләренең әлеге карары белән таныштырырга һәм аны тормышка ашыру чараларын күрергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**